**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы № 17 25 сентябрь 2017 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әсәй авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, "Әсәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, "Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында" Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 11 сентябрендәге 16 номерлы "Референдум уздыруны инициацияләү турында»гы карарын, Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2017 елның 11 сентябрендәге 16 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2017 елның 11 сентябрендәге 15 номерлы "Референдум уздыруны инициацияләү турында»гы карары нигезендә

Әсәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Әсәй авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2018 елда Әсәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы Сез?:
1) Әсәй, Митрәй авыллары юлларын кардан чистарту;
2) авыл җирлеге территориясен чүп үләннәреннән чистарту;
3) бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;
4) суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
5) янгын депосы бинасының электр энергиясе өчен түләү, янгын сүндерү машинасын тоту һәм ремонтлау;
6) Митрәй авылы мәдәният йортын ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карар рәсми матбугат басмасында - «Маяк» район газетасында басылып чыгарга һәм түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru, түбәндәге веб-адрес буенча Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http:/ aznakyevo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис Л.М. Вәлиева